
# Пәйгамбәребезнең ﷺ намаз уку сыйфаты

1

Имам һәм ялгыз гына намаз укый торган кеше алдында киртә (сутра) булса әйбәт. Имам артыннан намаз укучының киртәсе булып исә имамның киртәсе хезмәт итә;




Намаз укучы үзенең күз карашын сәҗдә урынына юнәлтә һәм намаз вакытында читкә борылмый;




1

Намаз укучы аякларын җилкәләре киңлегендә куя һәм аларны тышкы яктан тигезли;




2

Намаз укучы намазның барлык шартларын да үтәгәч, “Аллаһу әкбәр” дип намазга керү тәкбирен әйтә. Бу сүзләрне әйткәндә, бармакларны бер-берсе белән тоташтырып һәм уч төпләрен Кыйбла тарафына юнәлтеп, кулларны җилкәләр яки колаклар биеклегенә күтәрә;



3

Шуннан соң ул, уң кул чугын сул кул чугының аркасына, шулай ук беләзеккә һәм беләкләргә куя, яки уң кулы белән сул кулының беләзеген тота;



4

Соңыннан, тәкбирдән соң, намаз башында укылучы зикерләр (әл-истифтах) укылса, яхшы була. Төрлелек өчен, Сөннәттә килгән башка зикерләр укылса, тагын да әйбәтрәк була, һәм әйтә: «Субханә-кә, Аллаһуммә, вә бихәмди-кә, вә табәракә-сму-кә вә тә'әләҗадду-кә вә ла иләһә гайру-ка»


Шуннан соң намаз укучы “Әгузу би-Лләһи минәш-шәйтанир-раҗим” (истигәзә) сүзләрен әйтеп, Аллаһның яклавына сыена;

Шуннан соң: “Би-сми-Лләһи әр-Рахмәни әр-Рахим” сүзләрен әйтә, аннан “Фатиха” сүрәсен, бер генә аятен дә төшереп калдырмыйча, тулаем укый. Аятьләрне бер-бер артлы, рәттән, хәрефләрне, хәрәкәләрне, сүзләрне дөрес итеп әйтеп уку шарт; Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.1. Әл-хә́мду лил-лә́һи ра́ббил-гъа́ләми́н2. Әр-рахмә́нир-рахи́м3. Мә́лики йә́умид-ди́н4. Иййә́кә нә́гъбуду үә иййә́кә нәстәгъы́йн5. Иһдинә́с-сыйра́таль-мустәкы́йм6. Сыйрата́ль-ләзи́нә әнгъа́мтә гъалә́йһим7. Га́йриль-мәгду́би гъалә́йһим үә лә́д-да́льлин.

“Фатиха”дан соң “Коръән”нән тагын нәрсә булса да уку әйбәт. Бу очракта истигәзә әйтелми һәм әгәр уку сүрә башыннан башланса, бу очракта “Би-сми-Лләһи әр-Рахмәни әр-Рахим” сүзләрен әйтү кирәк;

5

Шуннан соң намаз укучы: “Аллаһу әкбәр”, – ди һәм рөкүгъка китә, һәм кулларын тезләренә куя, бу вакытта куллар терсәкләрдән бөгелми. Аның аркасы исә башы белән бер турыда булырга тиеш. Ул мәҗбүри рәвештә бер генә тапкыр булса да “Субхәнә раббиәл-газыйм” сүзләрен әйтергә тиеш, аннан соң Сөннәттә килгән башка зикер һәм догаларны өстәп әйтсә ярый;




6

Шуннан соң рөкүгътан турайган вакытта, тураеп беткәнче, намаз укучы “Сәмиа'Ллаһу лимән хәмидәһ” сүзләрен әйтә.

Шуннан соң тулысынча тураеп беткәч, ул: “Раббәнә үә ләкәлхәмд”, – ди. Шуннан соң ул Сөннәттә килгән башка зикер-догаларны әйтсә, яхшы була;


Моның соңында ул, кулларын күтәрмичә: “Аллаһу әкбр”, – ди һәм тәннең җиде өлеше: маңгай белән борын, уч төпләре, тезләр һәм ике аяк бармакларының эчке өлешләре белән сәҗдә кыла;

Сәҗдә вакытында намаз укучы кулларын ян-яклардан (ягъни алар тәнгә тиеп тормый), корсакны ботлардан, ә ботларны балтырлардан ерагайта, шулай ук терсәкләрне җирдән күтәрә;




7

Ул мәҗбүри рәвештә бер тапкыр гына булса да “Субхәнә раббиәл-әгълә” сүзләрен әйтә, аннан соң Сөннәттә килгән башка зикер һәм догаларны өстәп әйтсә ярый, шулай ук ул әгәр теләсә, башка дога сүзләрен әйтә ала, әмма ул Аллаһка пәйгамбәребездән (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) килгән сүзләр белән мөрәҗәгать итсә, тагын да яхшырак була;




8

Шуннан соң ул “Аллаһу әкбәр”, – ди һәм җирдә яткан һәм үзенә таба бөкләнгән сул аяк табаны өстенә, ә уң аякның табанын вертикаль рәвешкә китереп һәм аның бармакларын Кыйбла ягына каратып утыра, кулларын ботларының тезләргә якын өлешенә куя – шул рәвешле бөтен намазларда да утырыла. Бары өченче һәм дүртенче рәкәгатьләрдә генә “тауаррук” халәтендә – сул аягын уң аяк балтыры астына кертеп утыру кирәк;




9

Утырып торудан соң намаз укучы “Аллаһу әкбәр”, – дип әйтә һәм беренче тапкырдагы кебек үк сәҗдә кыла.Шуннан соң ул “Аллаһу әкбәр”, – дип әйтә һәм икенче рәкәгатькә торып баса. Аны беренче рәкәгать кебек үк үти, ләкин икенче рәкәгатьтә намазны ачучы тәкбир әйтелми һәм “истифтах” догасы кылынмый;



Намаз укучы икенче сәҗдәдән күтәрелеп, “тәшәххуд” кылу өчен утыра;


Уң кулының имән бармагын Кыйбла ягына юнәлтә һәм Аллаһтан ярдәм сорап, аны селкетә, ә урта һәм баш бармакларын бөкрә итеп тоташтыра;



Бу вакытта ул мәҗбүри рәвештә “тәшәххуд” һәм “салават” сүзләрен әйтә:
Әттәхияту лилләһи үәс-саләүәти үәт-тайибәт, әссәлә-му гәләйкә әййүһән-нәбийү үә рахмәтүллаһи үә бәракәтүһ, әссәләму галәйнә үә галә гый-бәдилләһис-салихин, әшһәду әллә иләһә иллАллаһу үә әшһәду әннә Мүхәммәдән габдүһү үә расүлүһ. Аллаһүммә салли галә Мүхәммәдин үә галә әли Мүхәммәд, кәмә салләйтә галә Ибраһимә үә галә әли Ибраһимә иннәкә хәмидүм-мәҗид. Аллаһүммә бәрик галә Мүхәммәдин үә галә әли Мүәммәд, кәмә бәрактә галә Ибраһимә үә галә әли Ибраһимә иннәкә хәмидүм-мәҗид.

Шуннан соң ул Аллаһтан дүрт бәладан: Җәһәннәм газапларыннан, кабер газабыннан, дөнья һәм үлем фетнәсеннән, Дәдҗәл коткысыннан саклану сорый (Аллаһуммә инни ә’узубикә мин ‘әзаби джәхәннәм, уа мин ‘әзабиль-къабр, уа мин фитнәтиль-мәхья уәль-мәмәт, уә мин шәрри фитнәтильмәсихи-ддәдҗҗәл) , шуннан соң намаз укучы Аллаһка башка дога сүзләре белән мөрәҗәгать итә ала, әмма ул Аллаһка пәйгамбәребездән (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) килгән сүзләр белән мөрәҗәгать итсә, тагын да яхшырак була, мәсәлән: “Йә Аллаһ, тиешле дәрәҗәдә Сине зикер кылырга, Сиңа шөкер итәргә һәм Сиңа гыйбадәт кылырга ярдәм ит миңа!” (Аллаһуммә, ә'ин-ни 'әлә зикри-кә, вә шукри-кә вә хусни ’ибәдәти-кә);

Шуннан соң ул уң якка да, сул якка да сәлам бирә, сәлам биргән вакытта җилкәләр борылмый, бары тик баш кына борыла (баш күтәрелми дә, төшерелми дә) һәм ян-якларга куллар белән күрсәтелми;



10

Әзерләүче : Хәйсәм бин Мөхәммәд Джәмил Сәрхән Пәйгамбәребез мәчетендәге укытучы һәм mahadsunnah.com сайтының җитәкчесе